КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 гыйнвар г.Казань № 60

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшь белгечләр – табибларга дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2012 ел, 9 июнь, 501 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшь белгечләр – табибларга дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2012 ел, 9 июнь, 501 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында «1 794,5 сум» сүзләрен «2 510,0 сум» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль районнары территориясендә урнашкан дәүләт автоном (бюджет) сәламәтлек саклау учреждениеләрендә яшь белгечләр –табибларга акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары территориясендә урнашкан дәүләт автоном (бюджет) сәламәтлек саклау учреждениеләрендә яшь белгечләр –табибларга акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибендә:

2 пунктта «югары һөнәр белеме бирүче мәгариф учреждениесен» сүзләрен «югары белем бирүче мәгариф оешмасын» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «белгеч сертификатына» сүзләреннән соң «яки белгечне аккредитацияләү турында таныклыкка» сүзләрен өстәргә, «югары һөнәр белеме бирүче мәгариф учреждениесен» сүзләрен «югары белем бирүче мәгариф оешмасын» сүзләренә алмаштырырга;

5 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

8 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт автоном (бюджет) сәламәтлек саклау учреждениесе» сүзләрен «дәүләт автоном (бюджет) сәламәтлек саклау учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «сәламәтлек саклау учреждениесен» сүзләрен «дәүләт автоном (бюджет) сәламәтлек саклау учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин